# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы
«Войкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең
Базяково торак пунктында
2024 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

**2023 елның 11 октябреннән** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Войкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Базяково торак пунктында гражданнар җыены

## КАРАР ИТТЕ:

1. 2024 елда Алексеевск муниципаль районының «Войкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендәге Базяково авыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 600 сум күләмендә үзара салым кертергә, 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына срoклы хезмәткә алынучы гражданнардан тыш.

2.Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

-торак пункт юлларын төзекләндерү;
-торак пункт юлларын кышкы һәм җәйге чорда карап тоту;
- торак пункт урамнарын карап тоту;
-урамнарны яктыртуны карап тоту;
-су белән тәэмин итү челтәрләрен карап тоту.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта Войкино авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә рөхсәт бирергә.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен, Войкино авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә , Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http:// alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Войкино авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Алексеевск муниципаль районы
Войкино авыл җирлеге башлыгы Н.П. Шабутдинова